КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1204

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 июнь, 608 нче; 2022 ел, 21 октябрь, 1130 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) раслага:

Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан өстәмә финанслана торган субсидия бирү тәртибен;

2022 елда бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчасы исәбеннән өстәмә финанслана торган субсидия бирү тәртибен.»;

әлеге карарга 2022 елда бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчасы исәбеннән өстәмә финанслана торган субсидия бирү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карар 2022 елның 13 ноябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 11 ноябрь, 1204 нче
карары редакциясендә)

2022 елда бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчасы исәбеннән өстәмә финанслана торган субсидия бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип 2022 елның 1 сентябреннән 31 октябренә кадәр үз җитештерүендәге бөртекле культуралар (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт сатып алу интервенцияләрен уздыру барышында авыл хуҗалыгы товары җитештерүчеләрдән һәм (яки) Россия Федерациясе территориясендә авыл хуҗалыгы товары җитештерүчеләр тарафыннан җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соң (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалардан һәм индивидуаль эшмәкәрләрдән авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу һәм реализацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 5 октябрендәге 1003 номерлы карары нигезендә дәүләт сатып алу интервенцияләрен уздыру барышында сайлап алуда катнашучылар тарафыннан реализацияләнгән бөртекле культуралардан тыш) җитештерүгә һәм аларны реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә (алга таба – сайлап алуда катнашучылар) 2022 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчасы исәбеннән өстәмә финанслана торган субсидия (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Бу Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр түбәндәгеләрне аңлата:

бөртекле культуралар – бодай, арыш, кукуруз, арпа;

сайлап алуда катнашучылар – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктлары эзлекле рәвештә күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2021 елның 9 октябрендәге 1722 номерлы карары белән расланган Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктлары эзлекле рәвештә күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасын булдыру, аны үстерү һәм эксплуатацияләү кагыйдәләре (Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктлары эзлекле рәвештә күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасында белешмәне һәм мәгълүматны теркәү һәм бирү кагыйдәләрен, белешмә һәм мәгълүмат бирү формаларын һәм форматларын, мондый системадагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүгә карата таләпләрне, шулай ук мәгълүмат бирү турында

грәсми сораулар җибәрү, шул исәптән гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән («Интернет» челтәрен һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү бердәм порталын да кертеп) файдаланып җибәрү формаларын һәм тәртибен кертеп) нигезендә Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктлары эзлекле рәвештә күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Ашлыкны эзлекле рәвештә күзәтеп бару федераль системасы) теркәлгән авыл хуҗалыгы товары җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан тыш), шулай ук фәнни, фәнни-техник һәм (яки) белем бирү эшчәнлеге барышында авыл хуҗалыгы продукциясен (бөртекле культураларны) җитештерүне, аны беренчел һәм аннан соң (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыра торган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары.

3. Субсидия бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

Субсидиянең финанс белән тәэмин итү чыганагы – максатчан билгеләнеше булган, сайлап алуда катнашучыларга бөртекле культуралар җитештерү һәм аларны реализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплаганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен өстәмә финанслау максатларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондыннан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы.

Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

4. Субсидия алучылар Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявка) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

5. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – рәсми сайт), сайлап алуны үткәрә башлау көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның һәм аның тиешле Татарстан Республикасы муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба – Идарәләр) исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почтасы адресын;

бу Тәртипнең 18 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) битләр күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 8 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 9, 10 һәм 11 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда һәм рәсми сайтта сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң булмаска тиеш.

6. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

бөртекле культуралар җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

7. Сайлап алуда катнашучы заявка бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән дә артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән, 300 мең сумнан артмаган йөкләмәсе булырга мөмкин;

сайлап алуда катнашучы юридик зат үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында

каралган тәртиптә туктатылмау, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы расланган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмау;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлар тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска тиеш.

8. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, тиешле сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) сайлап алуда катнашучы ризалыгы бирелгән заявканы;

заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтындагы Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

салым органының заявка бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән артмаган датага карата салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмавынраслый торган

белешмә кәгазен (сайлап алуда катнашучы тарафыннан мондый документ тапшырылмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала) яки салым органының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сум күләменнән артмаган, үтәлмәгән йөкләмә булуын раслый торган сайлап алуда катнашучыларның салымнары, җыемнары, иминият кертемнәре, пенялары, штрафлары, процентлары буенча исәп-хисаплар торышы турында белешмә кәгазен;

Ашлыкны эзлекле рәвештә күзәтеп бару федераль системасыннан 2022 елның 1 сентябреннән 31 октябренә кадәр үз җитештерүендәге бөртекле культураларны җитештерү күләмнәре турында белешмә;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктларын күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасында ашлык партиясенә яки ашлык эшкәртү продуктлары продуктлары партиясенә товарның иярчен документын рәсмиләштерү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 9 октябрендәге 1721 номерлы карары белән расланган Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктларын күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасында ашлык партиясенә яки ашлык эшкәртү продуктлары продуктлары партиясенә товарның иярчен документын рәсмиләштерү кагыйдәләре (алга таба – Товарның иярчен документын рәсмиләштерү кагыйдәләре) нигезендә рәсмиләштерелгән ашлык партиясенә яки ашлык эшкәртү продуктлары продуктлары партиясенә товарның иярчен документлары белән раслана торган 2022 елның 1 сентябреннән 31 октябренә кадәр үз җитештерүендәге бөртекле культуралар җитештерү һәм реализацияләү күләмнәре турында белешмә;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча хисап финанс елына үсемлекчелек продукциясен җитештерү, аның чыгымнары, үзкыйммәты һәм аны реализацияләү турында бухгалтерлык хисаплылыгы мәгълүматы нигезендә бөртекле культуралар җитештерүнең факттагы үзкыйммәте (чәчүлек өчен кулланылган бөртекле культуралар орлыгы, ашламалар, бактерияле һәм башка препаратлар, үсемлекләрне зыян салынудан саклау чаралары, барлык төрләрдәге сатып алу энергиясе, технологик максатларда кулланыла торган барлык төрләрдәге нефть продуктлары, төп чараларны ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, инвентарь, приборлар, кораллар һәм башка хезмәт чаралары, хезмәт өчен түләү, социаль кирәк-яраклар өчен акча тотып калу, төп чараларны амортизацияләү, башка төркемнәргә кертелмәгән чыгымнар) турында белешмә кәгазе;

Товарның иярчен документын рәсмиләштерү кагыйдәләре нигезендә рәсмиләштерелгән ашлык партиясенә яки ашлык эшкәртү продуктлары партиясенә товарның иярчен документлары белән раслана торган, 2022 елның 1 сентябреннән 31 октябренә кадәр үз җитештерүендәге бөртекле культураларны реализацияләү фактын раслый торган документлар (шартнамәләр, товар-транспорт накладнойлары һәм (яки) универсаль тапшыру документлары, реализацияләнгән продукцияләүгә түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре);

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия күләмен исәпләү;

Тапшырылган документларның күчермәсе сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан таныкланган, документларга имзалары куелган һәм мөһер (булганда) белән расланган булырга тиеш.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы, заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.

9. Идарә:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларны кабул итү срогы эчендә заявкаларны, аларның керү датасын һәм кергән көндәге вакытын күрсәтеп, «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында терки;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә тапшырылган документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә, ә сайлап алуда катнашучыларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган формалар буенча документлар реестрын, җыелма исәп-хисап белешмә кәгазен, заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында реестр формалаштыра һәм аларны Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша Министрлыкка җибәрә.

10. Министрлык:

заявкалар кабул итү срогы тәмамланган көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Идарәләр тарафыннан тапшырылган реестрлар нигезендә Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча заявкалар бирү чираты тәртибендә сайлап алу нәтиҗәләре турында (сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү турында йә заявканы алмау турында) җыелма реестр төзи;

сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм рәсми сайтта түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

11. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен нигезләр:

сайлап алуда катнашучыларның бу Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик зат урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявканың сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килмәве.

12. Министрлык бердәм порталда һәм рәсми сайтта сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән 15 эш көне эчендә субсидия алучылар белән Россия Федераиясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешү төзи.

Килешү «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итәлә торган дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү тәртибе;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплар бирү формалары һәм сроклары (кирәк булганда);

бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеген булдырмауга китерә торган итеп Министрлыкка киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән ризалашуга ирешә алмаганда килешүне өзү турында шарт (2022 елда килешүнең яңа шартларын, шул исәптән кирәк булганда, башкарма хакимиятнең билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы килешү ягы булып тормаган очракта, әлеге орган вәкилләре катнашында килештерү тәртибе).

Министрлык, кирәк булганда, субсидия алучылар белән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип танылa.

13. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә килешүләр төзүне төгәлләү срогы көненнән бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыларга субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия алучыларга субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә үз шәхси счетларыннан Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгында ачылган шәхси счетларына акча күчерә.

14. Идарәләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган үз шәхси счетына бюджет акчасы кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә субсидияләрне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучыларга ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.

15. Каплау максаты белән субсидияләнә торган чыгымнарның юнәлешләре – үз җитештерүендәге бөртекле культуралар җитештерүгә бәйле чыгымнар (чәчүлек өчен кулланылган бөртекле культуралар орлыгы, ашламалар, бактерияле һәм башка препаратлар, үсемлекләрне зыян салынудан саклау чаралары, барлык төрләрдәге сатып алу энергиясе, технологик максатларда кулланыла торган барлык төрләрдәге нефть продуктлары, төп чараларны ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, инвентарь, приборлар, кораллар һәм башка хезмәт чаралары, хезмәт өчен түләү, социаль кирәк-яраклар өчен акча тотып калу, төп чараларны амортизацияләү, башка төркемнәргә кертелмәгән чыгымнар).

16. Субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия күләме ($W_{ф}$) (сумда) исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$W_{ф} = \sum_{i=1}^{n} (V_{фi} \times C) \leq \sum_{i=1}^{n} (V_{фi} \times S_i \times 50\%),$$

монда:

i – бөртекле культуралар;

n – бөртекле культуралар саны;

$V_{фi}$ – 2022 елның 1 сентябреннән 31 октябренә кадәр сайлап алуда катнашучы тарафыннан реализацияләнгән үз җитештерүендәге i бөртекле культураның факттагы күләме (тоннада);

C – реализацияләнгән 1 тонна үз җитештерүендәге бөртекле культураларга субсидия ставкасы, аның күләме Министрлык боерыгы белән раслана һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = \frac{W_{б}}{R_{рф}},$$

монда:

$W_{б}$ – бу Тәртипнең 3 пунктындагы беренче абзацы нигезендә Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре күләме (мең сумда);

$R_{рф}$ – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында субсидия алучыларга бөртекле культуралар җитештерү һәм аларны реализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчасы исәбеннән Татарстан Республикасына башка бюджетара трансфертлар бирү турында төзелә торган килеәү нигезендә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы

тарафыннан билгеләнгән 2022 елда Татарстан Республикасы буенча үз җитештерүендәге бөртекле культураларны реалилзацияләү күләме (мең тоннада);

$S_i$ – хисап финанс елында җитештерелгән бөртекле культураларның үзкыйммәте (тонналы сумнарда), хисап финанс елында үсемлекчелек продукциясен җитештерү, аның чыгымнары, үзкыйммәте һәм аны реализацияләү турында бухгалтерлык хисаплылыгы мәгълүматы нигезендә хисап финанс елында җитештерелгән i бөртекле культураның үзкыйммәте (1 тоннага сумда).

Әгәр 2022 елның 1 сентябреннән 31 октябренә кадәр субсидия алучылар тарафыннан реализацияләнгән бөртекле культураларның факттагы күләме Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән 2022 елның 1 сентябреннән 31 октябренә кадәр Татарстан Республикасы буенча үз җитештерүендәге бөртекле культураларны реализацияләү күләменнән (мең тоннада) артып киткән булса, субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия суммасы (W) Министрлык тарафыннан түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = (V_{зк} \times К) \times С,$$

монда:

$V_{зк}$ – 2022 елның 1 сентябреннән 31 октябренә кадәр субсидия алучы тарафыннан реализацияләнгән, каплауга тәкъдим ителгән үз җитештерүендәге бөртекле культураларның факттагы күләме (мең тоннада);

К – субсидия алучы тарафыннан реализацияләнгән, каплауга тәкъдим ителгән, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган бөртекле культуралар күләмен корректировкалау коэффициенты:

$$К = \frac{R_{рф}}{\Sigma_{j=1}^{k} V_{зк}},$$

монда:

j – субсидия алучылар;

k – субсидия алучылар саны.

17. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан бирелгән документлар бу Тәртипнең 8 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү яки әлеге документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

18. Субсидия бирү нәтиҗәсе – 2022 елның 31 декабренә карата 2022 елның 1 сентябреннән 31 октябренә кадәр реализацияләнгән үз җитештерүендәге бөртекле культуралар күләме (мең тоннада).

Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән нәтиҗә күрсәткечен 2022 елның 31 декабренә карата нәтиҗәнең фактта ирешелгән күрсәткече белән чагыштырып карау нигезендә бәяләнә.

Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Министрлык, субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту

өлешендә килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.

19. Субсидия алучы субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Министрлыкка Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап тапшыра.

20. Бирелгән субсидия, субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракларда, Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты keремeнә кире кайтарылырга тиеш.

21. Әгәр субсидия алучы тарафыннан 2022 елның 31 декабренә карата килешүдә каралган субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү буенча йөкләмәләр бозган һәм субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап бирелгән датага кадәр кадәр әлеге бозулар бетерелмәгән булса, субсидия алучы субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр субсидияне түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләмдә ($V_{кайтару}$) кире кайтаруны тәэмин итәргә тиеш:

$$V_{кайтару} = (V_{акча} \times k) \times 0{,}01,$$

монда:

$V_{акча}$ – нәтиҗәгә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – түбәндәге формула буенча билгеләнә торган субсидияне кире кайтару коэффициенты:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткече;

S – субсидия алучы өчен килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече.

Субсидияне кире кайтару коэффициентын исәпләп чыгарганда, коэффициентның бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәгән дәрәҗәсе чагылдырыла торган уңай күрсәткечләре кулланыла.

22. Бу Тәртипнең 20 һәм 21 пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемeнә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

23. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

24. Субсидия алучылар тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык тиешле субсидия алучының тиешле вазыйфаи затларына йөкләнә.

25. Бюджет акчасыннан файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.